КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 июль г.Казань № 540

«Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2018 елда тормышка ашыру барышы һәм 2019 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2018 елда тормышка ашыру барышы һәм 2019 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе белән берлектә, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре өчен энергия саклауга һәм энергетика ресурсларыннан файдалануның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән хезмәтләр күрсәтүгә энергия сервисы контрактын (шартнамәсен) төзү хокукына конкурс документларының бертип формасын актуальләштерергә.

3. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына яктырту системаларын модернизацияләү, һава торышыннан чыгып җайга сала торган җайланмасы булган автомат индивидуаль җылылык пунктларын, һава торышыннан чыгып җайга сала торган җайланма узелларын урнаштыру эшләрен үткәрү өчен капиталь ремонт программасына кертү өчен бюджет өлкәсе объектлары исемлеген формалаштырганда әлеге исемлекне энергия сервисы

контрактлары механизмы аша югарыда күрсәтелеп үтелгән чараларны тормышка ашыру мөмкинлеге предметына Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килештерергә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, кулланунын факттагы күләмнәрен натураль чагылышта һәм гамәлдәге тарифны исәпкә алып, урам яктырту буенча энергетика ресурслары өчен түләү чыгымнары нормативларын исәпләүнең төзәтмәләр кертелгән методикасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына хисап кварталыннан соң килүче айның 25енә кадәр бюджет өлкәсендәге республика оешмаларының энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен кертүне тәэмин итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә энергия сервисы контрактлары төзү юлы белән энергия саклау чараларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрендә (булган очракта) энергия саклау чараларын энергия сервисы контрактлары механизмы аша өстенлекле тәртиптә гамәлгә ашырырга;

2019 елның 20 июленә кадәр 2018 ел һәм үткән хисап чорлары өчен энергетика декларациясен (шул исәптән Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләре буенча (булган очракта)) «Энергетика нәтиҗәлелеге» энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә тутыруны тәэмин итәргә;

2019 елның 1 августына кадәр энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә тармак программаларын (ярдәмче программаларны) гамәлдәге норматив хокукый һәм методологик документлар нигезендә эшләргә яки актуальләштерергә, шул исәптән әлеге программаларның (ярдәмче программаларның) гамәлдә булу вакытын 2022 елга кадәр озайтырга, шулай ук аларны раслауны һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларында урнаштыруны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

хисап кварталыннан соң килүче айның 25енә кадәр бюджет өлкәсенең энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан

Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен кертүне тәэмин итүне;

икътисадый максатка ярашлы булган очракта, Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрендә энергия саклау чараларын энергия сервисы контрактлары аша өстенлекле тәртиптә тормышка ашыруны;

2019 елның 20 июленә кадәр 2018 ел һәм үткән хисап чорлары өчен энергетика декларациясен (шул исәптән Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләре буенча (булган очракта)) «Энергетика нәтиҗәлелеге» энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә тутыруны тәэмин итүне;

2019 елның 1 августына кадәр муниципаль берәмлекнең энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге программаларын, ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге программаларын гамәлдәге норматив хокукый һәм методологик документлар нигезендә эшләүне яки актуальләштерүне, шул исәптән әлеге программаларның гамәлдә булу вакытын 2022 елга кадәр озайтуны, шулай ук аларны раслауны һәм муниципаль берәмлекнең һәм ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең рәсми сайтларында урнаштыруны тәэмин итүне.

9. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, Татарстан Республикасының энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә катнашу мөмкинлеген эшләргә.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасының энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә катнашуын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2017 елда тормышка ашыру барышы һәм 2018 елга бурычлар турында» 2018 ел, 11 июнь, 457 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

12. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Кәримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин